**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР №21**

**Ютазы ав.** «28» август 2023 ел

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге советы карарына үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

2022елның 17 сентябрендәге «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең «Депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында»гы 1015 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 санлы Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, «даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карары нигезендә Ютазы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 28 апрелендәге 10 номерлы карары-на түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 3 пунктында «унберенче» сүзен «10,36» саннарына алмаштырырга;

2 бүлекнең 1 пунктында «11 163» санын «12 688» санына алмаштырырга;

2 бүлекнең 6 пунктында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче кушымтаны күрсәтелгән карар нигезләмәсенә яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла ".

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми басылып чыгу юлы белән түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

ТР Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Н.Ф.Җәләев

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының акчалата түләү күләмнәре

| Вазыйфа исемнәре | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | шәһәр тибындагы бистәләр нигезендә төзелгән авыл һәм шәһәр җирлекләрендә |
| | 11 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19039 |